эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмалары исемлегеннән чыгып, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы сайлау;

9) гариза бирүчегә кирәкле һөнәр (белгечлек) буенча белем бирү программалар турында белешмәләр мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмалары исемлегендә булмаган очракта, гариза бирүчеләргә һөнәри белем бирү яки өстәмә һөнәри белем бирү турында килешү төзүне оештыру;

10) гариза бирүчегә сайланган белем бирү программасының эчтәлеге һәм вакытлары, белем бирү программасын үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре турында, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманың урнашкан урыны, анда бару схемасы, элемтә телефоннарының номерлары турында мәгълүмат бирү;

11) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы күрсәтеп, сайлап алынган белем бирү программасы буенча һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу турында киңәшне үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә яки булган һөнәр, белгечлек, квалификация буенча халыкның мәшгульлек хезмәте органнары ярдәмендә туры килә торган эш эзләүне дәвам иттерү турында бәяләмә рәсмиләштерү;

12) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә бирү, гариза бирүченең шәхси эшенә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәнең икенче нөсхәсен теркәп кую;

13) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмәдә тиешле киңәшләр булган очракта, һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу өчен белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмасына юллама рәсмиләштерү һәм гариза бирүчегә тапшыру;

14) башка җирлеккә һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу өчен юллаган вакытта гариза бирүчегә Халык мәшгульлеге турындагы законның 23 статьясының 2 пункты нигезендә финанс ярдәме күрсәтү;

15) административ процедураларны (гамәлләрне) башкару нәтиҗәләрен халыкның мәшгульлеге өлкәсендә дәүләт хезмәтләреннән файдаланучы затларның (физик затларның, эш бирүчеләрнең) регистрына кертү;

16) техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү;

17) дәүләт хезмәтен КФҮ, КФҮнең читтән торып эшләү урынында күрсәтү.

3.2. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, һөнәри белем бирү яисә өстәмә һөнәри белем алу чорында стипендия түләү тәртибе һәм шартлары турында мәгълүмат бирү, консультация бирү, гаризаны тутырганда ярдәм күрсәтү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

гариза бирүченең һөнәри белем алуга яки өстәмә һөнәри белем алуга, башка җирлектә укуны да кертеп, мохтаҗ булган сәбәпләрен ачыклый;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, башка җирлектә укуны да кертеп, һөнәри белем яисә өстәмә һөнәри белем бирү чорында стипендия түләү тәртибе һәм шартлары турында консультацияләр бирә;

(белгечлекне) тәкъдим итә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң иң күбе 5 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче белән башка һөнәр (белгечлек) буенча һөнәри белем бирүне яки өстәмә һөнәри белем бирүне килештерү.

3.9. Гариза бирүче сайлаган һөнәр (белгечлек) нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмалары исемлегеннән чыгып, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы сайлау

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары исемлегеннән чыгып, гариза бирүче сайлаган һөнәр (белгечлек) нигезендә, башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарга һөнәри белем бирү яки өстәмә һөнәри белем бирү турындагы килешүләр нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы сайлап ала.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң иң күбе 5 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүче сайлаган һөнәр (белгечлек) буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы билгеләү.

3.10. Гариза бирүчегә кирәкле һөнәр (белгечлек) буенча белем бирү программалар турында белешмәләр мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган белем бирү оешмалары исемлегендә булмаган очракта, гариза бирүчеләргә һөнәри белем бирү яки өстәмә һөнәри белем бирү турында килешү төзүне оештыру

Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмалары исемлегендә гариза бирүчегә кирәкле һөнәр (белгечлек) буенча мәгариф программалары турында белешмәләр булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә кирәкле һөнәр (белгечлек) буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмасы белән эшсез гражданнарга һөнәри белем бирү яки өстәмә һөнәри белем бирү турында килешү төзүгә һәм «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә мондый сатып алуны сатып алулар планына, товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу план-графигына кертү турында рәсми мөрәҗәгать рәсмиләштерә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң иң күбе 11 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшсез гражданнарга һөнәри белем бирү яки өстәмә һөнәри белем бирү турында гариза бирүче өчен кирәкле һөнәр (белгечлек) буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасы белән килешү төзүгә рәсмиләштерелгән рәсми мөрәҗәгать.

3.11. Гариза бирүчегә сайланган белем бирү программасының эчтәлеге һәм вакытлары, белем бирү программасын үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре турында, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманың урнашкан урыны, анда бару схемасы, элемтә телефоннарының

номерлары турында мәгълүмат бирү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече гариза бирүчегә мәгълүмат бирә:

сайланган һөнәр (белгечлек, белем бирү программасы) буенча белем бирүнең эчтәлеге һәм вакытлары турында;

һөнәр (белгечлек, белем бирү программасын) үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре турында;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың урнашу урыны, анда бару схемасы, элемтә өчен телефон номерлары турында.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң иң күбе 3 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: сайланган белем бирү программасының эчтәлеге һәм вакытлары, белем бирү программасын үзләштерүнең көтелгән нәтиҗәләре турында, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманың урнашкан урыны, анда бару схемасы, элемтә телефоннарының номерлары турында мәгълүмат бирелгән гариза бирүче.

3.12. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы күрсәтеп, сайлап алынган белем бирү программасы буенча һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу турында киңәшне үз эченә алган дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә яки булган һөнәр, белгечлек, квалификация буенча халыкның мәшгульлек хезмәте органнары ярдәмендә туры килә торган эш эзләүне дәвам иттерү турында бәяләмә рәсмиләштерү

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманы күрсәтеп, сайлап алынган белем бирү программасы буенча һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу турында бәяләмә яки булган һөнәр, белгечлек, квалификация буенча халыкның мәшгульлек хезмәте органнары ярдәмендә туры килә торган эш эзләүне дәвам иттерү турында бәяләмә рәсмиләштерә.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң иң күбе 3 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсмиләштерелгән бәяләмә.

3.13. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә бирү, гариза бирүченең шәхси эшенә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәнең икенче нөсхәсен теркәп кую

Халыкның мәшгульлек үзәге белгече 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында ике нөсхәдә бәяләмә әзерли, аның белән гариза бирүчене имзалатып таныштыра һәм бер нөсхәсен гариза бирүчегә тапшыра (җибәрә), бәяләмәнең икенче нөсхәсен шәхси эшкә терки.

Үтәү вакыты: процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң иң күбе 3 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бәяләмә бирү, икенче нөсхәсен гариза бирүченең шәхси эшенә беркетү.

3.14. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы бәяләмәдә тиешле киңәшләр булган очракта, һөнәри белем алу яки өстәмә һөнәри белем алу өчен белем

